СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　КАРАР

2024 елның 6 июне　　　　№13

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 17 номерлы (2023 елның 3 ноябрендәге 44 номерлы үзгәрешләр белән)карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 394 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына һәм нигезләрен төгәлләштерү максатларында җир салымы буенча дифференциаль ставкаларны куллану максатында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 15 октябрендәге 17 номерлы (2023 елның 3 ноябрендәге 44 номерлы үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 нче пунктның 7 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-1,1% Федераль һәм республика хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, федераль, республика һәм муниципаль бюджет (автоном) учреждениеләре милкендә һәм даими (сроксыз) файдалану хокукында булган административ биналарны, мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү объектларын, физик культура һәм спорт, мәдәният, сәнгать объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата».

2. Әлеге карарны торак пунктның Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 105 йорт буенча административ бинада, Совет урамы, 8 йорт буенча балалар бакчасы бинасында, Мельничная урамы, 23 йорт, Югары Чыршылы авылы ФАП бинасында, Горная урамы, 27 йорт, Мордовская Кармалка авылы, Совет урамы, 13 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы　　　　Н.Я.Хәйруллина